Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы учреждениеләре, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Чүпрәле муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

– Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясын гамәлгә ашыру һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждениеләрнең, предприятиеләрнең рәсми сайтларында мәгълүмат урнаштыру (алар булган очракта);

– Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә җитәкченең, аның урынбасарларының һәм предприятиенең баш бухгалтерының айлык уртача хезмәт хакы турында хисап елыннан соң килүче елның 10 мартыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирү.

3. Әлеге карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә һәм 2017 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.А. Тарнавскийга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башкарма
комитетының
20___ елның
"___"________________
______ номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Чүпрәле муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре (алга таба - тиешенчә - Тәртип, учреждение, предприятие) җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының айлык уртача хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең барлык кулланучылары өчен аңлаешлы формада бәян ителергә һәм хисап елыннан соң килүче елның 31 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш:

– Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында;

– «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждениеләр, предприятиеләрнең рәсми сайтларында (алар булганда);

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм учреждениеләрнең, предприятиеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылырга тиешле мәгълүмат составында учреждение яисә предприятиенең тулы исеме, вазыйфасы, җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 һәм 3 пунктларында каралган мәгълүмат составында яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән затлар коммуникацияләренең башка индивидуаль чараларын, шулай ук дәүләт серенә яисә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне күрсәтү тыела.

5. Муниципаль учреждение һәм предприятие җитәкчесе хисап елыннан соң килүче елның 10 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә билгеләнгән форма буенча мәгълүмат бирә.

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Чүпрәле муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә КУШЫМТА

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат тапшыру формасы**

______________________________________________________________________
(муниципаль учреждениенең, муниципаль унитар предприятиенең тулы исеме)

Хисап чоры ___________ ел

| № п/п | Вазифа | ФИО (тулысынча) | Уртача айлык хезмәт хакы күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |